Карары

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге Советы

2020 елның «19» феврале № 150

«Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге советы депутаты статусы турында» нигезләмә хакында» 2017 елның 08 июлендәге 60 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, гамәлдәге законнарга туры китерү максатларындаТатарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы авыл җирлеге советы КАРАР чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге советының 2017 елның 8 июлендәге 60 номерлы карары белән расланган Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге депутаты статусы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы Депутат:

1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;

2) түбәндәге очраклардан тыш, коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а)сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары

башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәр итеп, Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (сәяси партия идарәсендә, һөнәри берлек органында, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешманың сайланулы органы, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең съездда (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашудан тыш) катнашу;

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г)идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә муниципаль берәмлек булган оешманы гамәлгә куючы (катнашучы) муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен оешманы гамәлгә куючының муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен йә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә тапшыру;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә, мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш. Шул ук вакытта укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый;

4)Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтү советлары, коммерциячел булмаган хөкүмәтнеке булмаган чит ил оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә аларның структур бүлекчәләре составына керергә;

5) граждан, административ яки җинаять эше яки административ хокук бозу эше буенча яклаучы яисә вәкил (законлы вәкиллек очракларыннан тыш) буларак катнашырга.»хокуклы түгел.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы,Тәмте авылы, 2 нче Октябрь ур., 50 нче йорт (Мәдәният йорты);

- ТР, Кама Тамагы районы, Октябрь ур., 65 йорт ( Авыл җирлеге администрациясе бинасы),

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга .

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам

Кама Тамагы муниципаль районының
Тәмте авыл җирлеге башлыгы
Кама Тамагы муниципаль районының
Тәмте авыл җирлеге Советы рәисе И.А. Зиновьев